## ДИЛБӘР, ДИЛБӘРКӘЕМ

*сүзләре һәм көе – Шамил Сагаутдинов*

1. Таң җилләре искән чакта
   Су өсте дулкынлана.
   Дулкын булып, яшь йөрәгем
   Өзгәләнә, моңлана.

**Кушымта:**

Эх, Дилбәр, Дилбәркәем!
Синнән башка яшәүнең лә
Тоймыйм һич ямен, тәмен дә,
Минем назлы гөлкәем!

Эх, Дилбәр, Дилбәркәем!
Яралама йөрәгемне!
Синең нурлы йөзләреңне,
Синең татлы сүзләреңне,
Сөю тулы күзләреңне,
Әйтче, ничек онытаем?

2. Бергә үстек, бергә йөрдек,
   Вәгъдәләштек мәңгегә.
   Әйтче: нигә күңелкәең
   Кинәт төште бүтәнгә?

**Кушымта.**

3. Маңгай күзе алдаса да,
   Күңел күзе алдамас.
   Белеп тор: синең күңелең дә
   Хатасын сизми калмас!

**Кушымта.**

**Дильбар, Дильбарушка**

Песня посвящена девушкам по имени Дильбар.

Эх, Дильбар, Дильбарушка! Без тебя я не чувствую вкуса к жизни! Не рань моё сердце! Разве смогу я позабыть твой лучистый лик, твои нежные слова, твои глаза, полные любви?